ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 марта 2017 г. № 1179

2017 елның язгы чорында Яр Чаллы шәһәренең жирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында

Уңайсыз табигать-климат шартлары барлыкка килү чорында Яр Чаллы шәһәренең жирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итү максатында һәм автомобиль юлларының конструктив элементлары ныклыгы кимү сәбәпле, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Автомобиль юллары турында һәм Россия Федерациясендә юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль закон, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яки муниципальара, жирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 нче Карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2017 елның 15 апреленнән 14 маена кадәрге чорга Яр Чаллы шәһәренең жирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында күчәрләргә яки күчәрләр группасына (арбага) төшүче рөхсәт ителгән авырлыклары арткан транспорт чараларының хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чорда жирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларындагы хәрәкәт, гамәлдәге законнар нигезендә махсус рөхсәт рәсмиләштерең, Яр Чаллы шәһәренең автомобиль юлларына зыян килү шартларында гамәлгә ашырылуны билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чорга транспорт чарасының һәр күчәренә яки күчәрләр группасына (арбага) рөхсәт ителүче авырлыкны түбәндәгечә билгеләргә:

1) бер күчәрле – 6,0 тонна;

2) ике күчәрле – 5,0 тонна;

3) өч күчәрле – 4,0 тонна.

4. Әлеге карарның 1 пункты түбәндәге очракларга кагылмауны билгеләргә:

1) «Автомобильләрдә йөк ташуны гамәлгә ашыруга дәүләт контроле турында һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында» 1998 елның 24 июлендәге 127-ФЗ санлы Федераль законлагы Нигезнамәгә туры китереп гамәлгә ашырыла торган халыкара йөк ташу;

2) автобусларда, шул исәптән халыкара пассажирлар йөртү;

3) азык-төлек продуктлары, хайваннар, дарулар, орлык фонды, ашламалар, почта һәм почта йөкләре ташу (әлеге пунктчада күрсәтелмәгән йөкләр белән бергә ташудан тыш);

4) ягулык (бензин, дизель ягулыгы, судно ягулыгы, реактив двигательләр өчен ягулык, ягулык мазуты, газ хәлендәге ягулык) ташый торган йөк күтәрүчәнлеге 16 тоннага кадәр булган транспорт чаралары;

5) бәла-казаларның яки гадәттән тыш хәлләрнең аянычлы нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәкле йөк ташу;

6) авария-торгызу һәм ремонт эшләре үткәргәндә файдаланыла торган юллар төзү һәм юл-файдалану техникасын һәм материалларын ташу;

7) федераль закон нигезендә хәрби хезмәт күздә тотылган федераль башкарма хакимият органнарының транспорт чаралары;

8) автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен язгы чикләү чорында Татарстан Республикасының региональ әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында хәрәкәт итүгә махсус рөхсәте булган транспорт чаралары.

5. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә, транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорына урап узу маршрутын кушымтада каралганча билгеләргә.

6. Яр Чаллы шәһәренең «Автомобиль юллары предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1) региональ яки муниципальара, җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яки туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә, өстәмә мәгълүмат билгеләре булган тиешле юл билгеләре урнаштыру;

2) Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында йөрүгә махсус рөхсәтләр бирү пунктлары оештыру;

3) әлеге карарның 1 пункты нигезендә, хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорына үлчәү контроле һәм транспорт чаралары хәрәкәтен контрольдә тоту постлары оештыру.

7. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә:

1) Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында 2017 елның язгы чорында уңайсыз табигать-климат шартлары барлыкка килү вакытында Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында мәгълүмат урнаштырырга;

2) әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырырга;


3) гамәлдәге законнар нигезендә махсус рөхсәтләр бирүне тәэмин итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ә. Кыямовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — В.А. Гаврилов

Приложение
к постановлению
Исполнительного комитета
от "__" _______ 2017г. №____

# ТРАНСПОРТНАЯ СХЕМА
г. Набережные Челны




Руководитель Аппарата
Исполнительного комитета ______ Г.К. Ахметова